РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» декабрь 2022г. г. Альметьевск № 93

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү һәм башка естәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хезмәткәрләрне системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, шулай ук шәһәрнең җирле үзидарә органнары коллективларында сәламәт яшәү рәвеше традицияләрен булдыру максатында,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2016 елның 10 августындагы 42 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен бүләкләү һәм башка естәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына (2016 елның 6 октябрендәге 48 номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 61 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 121 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 167 номерлы, 2021 елның 22 июлендәге 41 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 73 номерлы, 2022 елның 31 октябрендәге 84 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

а) 1 бүлекнең 1.4 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һөнәри эшчәнлекнең югары нәтиҗәлелеге һәм теп вазыйфаи бурычларга карамый торган йөкләмәләрне яки бурычларны сыйфатлы үтәве өчен бер вазыйфаи окладтан ике айлык акчалата түләүгә кадәр (3 бүлегенең 3.1 пунктындагы унбишенче абзацыннан тыш, спорт ярышларында призлы урыннар белән шөгыльләнү, шулай ук аларда катнашу өлешендә)».

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре Спартакиадасы программасына керүче һәр аерым спорт төре өчен призлы урыннар алган өчен түбәндәге премия күләме билгеләнә:

1 урын өчен - 80 460 сум;

2 урын өчен - 57 472 сум;

3 урын өчен - 34 483 сум;

Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасы ярышларында катнашкан өчен 57 472 сум күләмендә премия билгеләнә.»;

б) 3.1 бүлекнең 3.1 пункты унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-спорт, мәдәни, фәнни һәм башка юнәлешләрдәге ярышларда, конкурсларда һәм башка чараларда призлы урыннар алу, шулай ук аларда катнашу;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Ф.А. Шәйхетдинова).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов